ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Мөслим муниципаль районы
Метрэй авыл җирлеге
Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Митряевского сельского поселения Муслюмовского муниципального района

*423970 РТ. Муслюмовский район, с.Митряево ул. Кооперативная дом 52*
Mitr.Mus@tatar.ru тел.*8(8-5556)3-25-38*
ИНН 1629001096,КПП 162901001,ОГРН 1021605558424,ОКАТО 92242835000

Метрэй авылы

«09» 01 2019 г

ПОСТАНОВЛЕНИЕ №1

КАРАР №1

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Метрәй авыл җирлегендә**
**2019 елда үзара салым түләүне һәм җыюны оештыру һәм үзара салым акчалары тотыла торган төзекләндерү чаралары исемлеге турындагы карары**

"Җирле референдум, турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Метрэй авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрэй авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә 2019 елда Татарстан Республикиасы Мөслим районы Метрэй авыл җирлегендә бер тапкыр түләү (үзара салым) акчаларын үз вакытында җыю максатыннан
Карар бирәм:
1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының " Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлегендә 2019 елга, референдумда тавыш бирү хокукына ия, 18 яше тулган һәр авыл җирлегендә теркәлгән яшәүчегә 1000 сум күләмендә бер тапкыр түләү (үзара салым) күләмен расларга.
2. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, I, II төркем инвалидлары, АДР да,хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, нурлы авыру алган яки кичергән гражданнар, башка авырулар һәм инвалидлар өчен аны 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә кирәк.
3. Бер тапкыр түләү вакытын 2019 елның 01 апрелөнә кадәр расларга кирәк.
4. Авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карар буенча үзара салым акчаларын җыюны оештырырга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.
5. Үзара салым акчасы тотыла торган төзекләндерү буенча чаралар исемлеген расларга. (1нче кушымта)
6. Авыл җирлеге башкарма комитетына үзара салым акчаларын исемлектәге төзекләндерү эшләренә тотарга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.
7. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Метрәй авыл җирлеге битендә түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://muslumovo.tatarstan.ru/rus/mitr.htm
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге
башлыгы урынбасары

Гизтдинов Ф.Я.

Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге башлыгының № 1 карарына 1 кушымта
« 09» 01. 2019 ел.

Метрәй авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы тотыла торган төзекләндерү буенча чаралар исемлеге

1. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

2. Халыкның ялын оештыру һәм хезмәт күрсәтү мәдәният оешмалары белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

3. Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

4. Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру;

5. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә төзекләндерүне оештыру;

6. Урам-юл челтәре элементларына, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исем бирү;

7. Җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

8. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

9. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү;

10. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

11. Җирлек халкы күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми кулланылыштагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү дә.

12. Җирлекләрнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;

13. Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чараларны гамәлгә ашыру.

Авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Гизтдинов Ф.Я.